КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 май г.Казань № 394

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1173 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1173 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 июнь, 499 нчы; 2017 ел, 9 октябрь, 772 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин